ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НЫРТЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

# КАРАРЫ

19 декабрь 2023 ел №29

Нырты авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Нырты авыл җирлеге Советы карар бирде:

1. Нырты авыл җирлеге Советының 2018 елның 27 апрелендәге 4 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (2018 елның 12 ноябрендәге 24 номерлы, 2019 елның 16 маендагы 9 номерлы, 2020 елның 19 мартындагы 6 номерлы, 2021 елның 25 мартындагы 5 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 13 номерлы, 2023 елның 27 февралендәге 1 номерлы, 2023 елның 31 октябрендәге 25 номерлы үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 нче бүлекнең 11 нче пунктында икенче җөмләне төшереп калдырырга

1.2. 4 нче бүлекнең 18 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«18. Муниципаль хезмәткәргә классны чин бирү турында карар, әлеге бүлекнең 12 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән очраклардан тыш, барлык кирәкле документлар белән бергә Нырты авыл җирлеге башлыгына классны чин бирү турындагы тәкъдимнәр кертелгәннән соң, бер айдан да соңга калмыйча кабул ителергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә htth://kukmor.tatarstan.ru веб-адресы буенча Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Нырты авыл җирлеге территориясендәге мәгълүмат стендларында бастырырга.

Нырты авыл җирлеге башлыгы Т.А.Котдусов